**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«28» июль 2021 ел** **№ 168**

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 28 апрелендәге 144 номерлы «Спорт өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (2020 елның 25 августындагы 220 номерлы карар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 13 апрелендәге 242 номерлы «Дәүләт йөкләмәсе (заказ) электрон формада урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган социаль әһәмиятле дәүләт хезмәтләре, хезмәтләр күрсәтүгә күчү чаралары планын раслау турында» карарын үтәү йөзеннән карар итә:

1. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 28 апрелендәге 144 номерлы «Спорт өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» карарына (2020 елның 25 августындагы 220 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Расларга:

1.1. 1 нче кушымта нигезендә спорт разрядын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын;

1.2. 2 нче кушымта нигезендә, спорт судьясының квалификация категориясен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын.

2. Әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә, «Спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» дигән 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә,

3. Әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә ,«Спорт судьясының квалификация категориясен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» дигән 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

4. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
икътисад һәм финанслар буенча җитәкче урынбасары О. Н. Газизова